**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.10.2022 Балык Бистәсе штп. № 285пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 31.05.2022 ел, №108пи карары белән расланган җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 15.08.2022 ел, №1415 карары нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 31.05.2022 ел, №108пи карары белән расланган җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына (алга таба-регламентлар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Регламентларның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

"Формалаштырылган запросны формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер соратып алу формасындагы юлларны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Әгәр бердәм портал электрон форманың дөрес тутырылмаган юлларын ачыкласа, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны төзәтү тәртибе сорауның электрон формасында мәгълүмати хәбәр юлы белән хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Л.В. Кәримуллинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Ислямов